**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** с. Тюлячи **БОЕРЫК**

«27» ноября 2018

№ 306

Район күләмендә уздырыла торган «Минем елларым – минем байлыгым» нигезләмәсен раслау

2018 елның 19нчы ноябрь 62нче номер район Башкарма комитеты мәдәният бүлеге җитәкчесе хатын карап, "Россия Федерациясе җирлеге үзидарәсенең гомуми принципларын оештыруы турында" 2003 елның 5 октяберендәгы 131 нче номерлы Федераль закон нигезендә,

1. Кушымта нигезендә, Район күләмендә уздырыла торган «Минем елларым – минем байлыгым»нигезләмәсен расларга.
2. «Татмедиа» ААҖ «Теләчеинформ» мәгълүмат үзәгенә (Хужин Л.Й.) конкурс чараларын үткәрү турында җирле массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны тәкъдим итәргә.
3. Күрсәтмәнең үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенен социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.А. Нурмөхәмәтовка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хамидуллин

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
“27” ноябрь 2018 елның № 306
боерыгына кушымта

**Өлкәннәр көненә багышланган “Минем елларым-минем байлыгым” конкурсын үткәрү турында нигезләмә**

Әлеге нигезләмә “Минем елларым - минем байлыгым” конкурсын үткәрү тәртибен һәм шартларын билгели.

## 1. Конкурсны оештыручылар

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге.

Теләче муниципаль районында “Бөтендөнья татар конгрессы” иҗтимагый берләшмәсе берлеге.

Теләче муниципаль районында “Ак калфак” татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы.

## 2. Конкурсның максатлары һәм бурычлары

1. “Минем елларым - минем байлыгым” бәйгесен үткәрү максаты булып - гаиләң өчен мәхаббәт һәм горурлык хисләре, өлкән буынга хөрмәт тәрбияләү, өлкән яшьтәге кешеләрне районның мәдәни һәм иҗтимагый тормышында актив катнашуга тарту тора.

## 3. Фестивальдә катнашучылар

1. Конкурста Өченче буын хатын-кызлары һәм аларның ярдәмче төркемнәре катнаша ала.

## 4. Фестивальне үткәрү тәртибе һәм шартлары

1. Конкурс ике этапта үткәрелә.

1 этап - сайлап алу этабы - 2019 елның 1 октябренә кадәр Теләче муниципаль районы авыл җирлекләрендә уза.

2 этап – “Финал”. Конкурсның финалы 1 октябрь көнне, сайлап алу турлары җиңүчеләре белән район мәдәният йортында узачак.

Финалда катнашучылар 4 (дүрт) конкурс сынавы узачак:

- “Таныш булыйк” - катнашучыларның мавыгулары турында видеопризентацияләр – регламент - 3 минут;
- “Тәмле тамак” - конкурста катнашучылар тамашачыларга үзләренең кулинария осталыкларын тәкъдим итәргә тиеш;
- “Әбием экиятләре” - экиятләрдән миниатюралар – регламент - 5 минут;

- “Йолдызлы сәгать” - иҗади номер (вокал, бию, нәфис уку һ.б.) - 5 минут;

- “Яңа образ-авторлык коллекциясе” - костюмнар конкурсы.

**5. Бәяләү критерийлары**

1. Конкурста катнашучыларны сайлап алу критериясе - башкару дәрәҗәсе югары булу, артистлык, сәхнә культурасы һәм оригинальлек.

**6. Жюри составы**

1. Жюри составына мәдәният, мәгариф, сәнгать бүлеге белгечләре, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм, җәмәгатьчелек вәкилләре, конкурсны оештыру комитеты тарафыннан чакырылган оешма-партнерлар җитәкчеләре һәм иганәчеләр керә.

**7. Фестивальдә катнашучыларны бүләкләү**

1. Конкурсның төп җиңүчесенә “Гаҗәеп Әби 2019” исеме, ә конкурсның калган катнашучыларына төрле номинациядә махсус исемнәр бирелә:

- “Иң сөйкемле әби – 2019”;
- “Иң талантлы әби – 2019”;
- “Иң яхшы хуҗабикә2019”;
- “Иң элегант әби – 2019”;
- “Иң креатив әби – 2019”;
- “Иң бай әби – 2019”;
- “Иң заманча әби – 2019”;
- “Иң тапкыр әби – 2019”.

2. Финанслау бюджеттан тыш җәлеп ителгән акчалар хисабына башкарыла.

Кушымта

Өлкәннәр көненә багышланган
“Минем елларым-минем байлыгым” район конкурсын оештыру комитеты составы

Оештыру комитеты рәисе:

Нурмөхәммәтов А.А. - Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары.

Оештыру комитеты әгъзалары:

Иксанов Д.С. - Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге җитәкчесе;

Дәвләтшина А.Н - Теләче муниципаль районында “Бөтендөнья татар конгрессы” иҗтимагый берләшмәсе берлеге җитәкчесе;

Ибраһимова З.В - Теләче муниципаль районында “Ак калфак” татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы җитәкчесе.